**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ЕГОРЬЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422621 д.Каипы
ул. Центральная д.50
тел: 8-(84378)-3-36-19
факс: 8-(84378)-3-36-19
Egor.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ЕГОРЬЕВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422621 а.Каипы
Центральная урамы, 50 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-36-19
факс: 8-(84378)-3-36-19
Egor.La@tatar.ru

**2023 елның 12 декабре** **58 номер**

## КАРАР

**«Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 48 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 48 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 **2 пунктның 2.1 пунктчасының «в» абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннарын һәм инвалидларын;»

2. Әлеге карарның нигезләмәләренең гамәлдә булуы, 2023 елдан башлап салым чорлары өчен җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Егорьево авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Егорьево**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Б.Зарипов**